**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлегенең Әхмәт авылы торак пунктында гражданнар җыены**
**КАРАРЫ**

**10 апрель 2024 ел** **№ 6**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Әхмәт авыл җирлегенең Әхмәт авылы торак пункты гражданнары җыены

КАРАР ИТТЕ**:**

1. 2024 елда Нурлат муниципаль районының Әхмәт авыл җирлеге Әхмәт авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 1нче төркем инвалидлардан, бачактан инвалид булганнардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, СВОда катнашучылардан, 85 яшьтән өлкәнрәк ялгыз яшәүче гражданнардан кала, һәр балигъ булган кешедән 2000 сум күләмендә үзара салым кертергә әлеге акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкару буенча мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- Әхмәт авылы чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту;
- урам яктырту җайланмасы.

Халык җыенында рәислек итүче: Г.Н. Лизратова

Әхмәт авыл җирлеге башлыгы: Г.Н. Лизратова